

ISSN 0868-4545

Салават күпере

Сәер генә уйлар килә башка,
Кинәт кенә йолдыз атылганда:
Малай чакта күккә аткан уклар
Тиде микән әллә йолдызларга?..

Марсель ГАЛИЕВ.



Балачак балкышы – күңелләр алкышы

Әһә-һә-әй!
Ишетәсеңме син, яланаяклы малай!?
Ишетәсеңме син, яланаяклы кызый!?
Әһә-һә-әй!
Ишетәсезме сез, ваемсыз балачакның тынгысыз җаннары!?
Әһә-һә-әй!
Ишетәсезме сез, самими бала чагыгызны һәрдаим сагынып яшәүче хөрмәтле абыйлар-апалар, кадерле әтиләр-әниләр, мөхтәрәм бабайлар-әбиләр!?

Сезне, барчагызны, шигъри-әкияти төсләр тантанасын, кызыклы вә тылсымлы-могҗизаи Нәфис Сүзләр манзарасын тамаша кылырга чакырабыз.

Тамаша авторы – күренекле шагыйрь һәм язучы, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе **Марсель Баян** улы **ГАЛИЕВ.**


Әлеге күңелле Тамаша, инде аңлагансыздыр, шәт, «Салават күпере» «сәхнәсе»ндә була.

Була, дип... Бара бит инде ул тамаша – күрмисезмени!?

Җайлап кына утырыгыз,
Урыннарыгыз – «залда»...
Әле сезне сюрпризлар –
Бүләкләр көтә алда!


Шагыйрь Абыйның тамаша алдыннан әйткән сүзләре:

– Менә мин мең тармаклы мәһабәт әкият агачы астында басып торам. Яфракларында җемелдәгән мең тамчының берсен Җил тәгәрәтеп төшерә дә... учымда тамчы Салават күпере төсләренә таркала... Бу тамаша – шул тамчының бер балкышы түгелме?!



© "Салават купере", 2007 ел

Тамаша



Әтәч койрыклы кәҗә
Сакалын җирдән сөйри.
Сакалга басмас өчен,
Артка чигенеп йөри.




Алты мөгезле сыер
Аклы-каралы туннан.
Һәр мөгезнең иң очына
Берәр сыерчык кунган.



Кара күзлекле Муйнак
Китап тоткан, күр әнә!
Мәчене куркытмаска
Өрү фәнен өйрәнә.

Өчаяклы ата каз,
Бүреген кыңгыр салып,
Чәлдер-чөлдер күркәне
Күзәтә хәйран калып.

Җилпәзә җәйгән күркә
Сикертә кашсыз кашын.
Кай ара сарык белән
Алышкан нәни башын.





Сары томшыклы чеби
Тилгәнгә куйган капкан.
Оя ясаучы карга
Юан бүрәнә капкан.

Өй кыегында кояш
Авыз кыйшайтып көлә.
Кармак тотып түбәгә
Сак мәче менеп килә.

Бу ни тамаша, диеп
Кызыксынсаң син әгәр:
Минем рәссам энекәш,
Була, дип, шундый хәлләр,
Альбомын ачып ташлар,
Мин шулай күрәм, диеп,
Кызып аңлата башлар.



Рәссам Алла АЙСИНА

Кадерле дуслар!
Сезнең белән дә күңелле хәлләр-тамашалар булганы бардыр. Шулар хакында җәһәт кенә язып, журналханәгә хат юллагыз. Иң кызыклы язма иясенә – Шагыйрь Абыйдан бүләк!



Мин хәтерлим сине, шаян малай!
Йөртәсеңдер әле һаман шулай
Сыңар япьле пәке кесәңдә.
Гөрләвекләр буйлап килеп чык бер
Ак җилкәнле кәгазь көймәңдә.

(«Малай чакка хат» шигыреннән.)


Үсәргә телим

Җир астыннан йөри бөҗәк
Үзе белгән юллардан.
Өстәрәк – кара мыеклы
Тычкан кайта сунардан.

Өстәрәк – арыш басуы
Сары диңгез төсендә.
Өстәрәк – тургай атына
Ак нурлар сиртмәсендә.

Өстәрәк – мәтәлчек атып,
Уйный шаян болытлар.
Өстәрәк – кояш бишеге,
Төнен ай һәм йолдызлар.

Өстәрәк, биектәрәк,
Чиксезлеккә җитәрәк
Тагын ни бардыр, белмим.
Белмәгәнемне белергә
Тизрәк үсәргә телим!



Рәссам Светлана ПРИВИНА



Альбомдагы рәсем

Муйнак ята телен салындырып,
Мыраубикә аның сыртында.
Песи тирәсендә бөтерелә –
«Чи-чи» килгән тычкан да монда!

Минем рәсем белән килешмичә,
Барсы кинәт дәррәү кузгалды.
Берсен-берсе куып чыктылар да
Альбом бите бушап та калды.

Тычкан шылды койма асларыннан,
Песи менде капка башына.
Еш-еш сулап, Муйнак күзли аны
Кырын ятып баскыч ташына.

Мин ясаган сурәттәге сыман,
Дуслар булып кына калсалар;
«Чи-чи», «Мырау», «Өтер койрык» бергә
Кызык итеп уйный алсалар,

Дүрт тәпиен кырык тәпи итеп,
Тычкан куркып чабар идеме?
Ә песинең, куып җитеп Муйнак,
Койрык очын кабар идеме?

Әлсерәгәч Муйнак, тел очыннан
Бал кортлары чагар идеме?
Үпкәләп, мин альбомымның шунда
Бүтән битен ачар идемме?..



күңелләр бәйрәм итә

Әни әйтә

Фазыл Хөсню Дагларжадан

Мин йоклаган чакта
Күзләрем очып китә дә
Йолдызлар була икән.

Мин йоклаган чакта
Кулларым очып китә дә
Ботаклар була икән.

Мин йоклаган чакта
Тавышым очып китә дә
Кошка әйләнә икән.


Алып кит еракка

Арысам, әтием
Утырта иңенә.
Кулларым күктәге
Болытка үреләлә.
Әй, болыт, ак болыт,
Ал мине, иел дә,
Алып кит еракка,
Әкият иленә!

Әтине, әнине
Мин озак көттермәм.
Ак атта кайтырмын
Әкият иленнән.
Ак болыт ишетте,
Иелә төште дә:
– Бүген, – ди — килермен,
Көт мине төшеңдә...

Рәссам Диләрә НӘҮРҮЗОВА





«Салават күпере» «сәхнәсе»ндә күренешләр, декорацияләр алышынып кына тора. Түрдә янә Шагыйрь Абый пәйда була.



Шагыйрь Абый сөйли:

– Язасы килү теләге сокланганда һәм сагынганда килә. Кәгазь каршында үзалдыма елмаеп уйланам.

Туган җиреннән еракка киткәч, Африка малайлары крокодилларны сагынып искә төшерәләр микән? Бигрәкләр дә куркыныч су җәнлекләре бит. Сурәтен күргәч тә тәнең өшеп китә. Корбанына ыргылган чакта, телевизор экранын ватып чыгып, бүлмәңә килеп төшәр шикелле, артка чигенеп куясың.

Юлбарыс, арысланнарын күр инде, нинди гаярьләр! Фил, бизон, гиппопотам... тагын әллә ниләр... һәммәсе дәһшәт чәчеп тора. Жираф кына юаш-ягымлы күренә, шунысы кыен: яратып муеныннан сыйпар өчен аңа баскыч куярга кирәк.

Яраталардыр Африка малайлары, бу кыргый җәнлекләрнең дә ниндидер йогышлы-уңай сыйфатлары, сөйкемле сөякләре бардыр. Һәркемнең дә туган ягы үзенә газиз. Туган җир – әнкәң кебек үк бер генә, бердәнбер, аны сайлап алмыйлар.

Минем дә туган авылым, инешем, тау-үзәннәрем, урман-тугайларым, ерак киткән саен кечерәя барып, нәни генә хәтер йомгагына әверелеп, күңелемә күчкән. Шул йомгак җебе буйлап еллар аша кайтырга иде дә балачак хәятының капкаларын ачып керергә иде...



Үсеп җиткәч, дөнья гизеп,
Танышырбыз ил белән...

Танышу нидән башлана?

Ни генә юк бу чормада:
Иске урак дисеңме,
Чабагачлар, шүре, киле –
Бар да серле исемле.


Бабайлардан калган әйбер
Почмакларга өелгән.
Тузаннарын кагып алам –
Танышам мин өй белән.

Ни генә юк авылымда:
Тәмле чишмә сулары,
Кәҗә сукмагыннан менсәң,
Җил сызгырта таулары.

Каен урманына кадәр
Күпме өйләр тезелгән.
Санап чыгам морҗаларын –
Танышам авыл белән.

Бормалы юллардан китеп,
Ил буйлап йөрсәң иде.
Диңгез, таулар һәм тайгалар,
Шәһәрләр күрсәң иде.

Серләр челтәреннән торган
Картага мин иеләм.
Үсеп җиткәч, дөнья гизеп,
Танышырмын ил белән.



Рәссам Светлана ПРИВИНА



Шагыйрь Абыйның туган җире – гүзәл Чатыр таулы Азнакай районы, Балтач авылы. Биредә ул 1946 елның 8 октябрендә якты дөньяга килә. Түбәндәге шигырендә ул менә шул төбәкнең үзгә бер матурлыгын тасвирлый. Шигырьне игътибар белән укып чыгыгыз да, үзегезнең туган авылыгыз, районыгыз (яисә туган шәһәрегез) турында шигъри тел белән бәян иткән язмаларыгызны «Салават күпере»нә юллагыз. Кызыклы язма авторларын шулай ук истәлекле бүләкләр көтә!

Туган як



Шундый як ул, карагыз сез
Минем туган җиремә:
Йолдызлар хәтта кызыгып
Тәлгәш-тәлгәш сибелә.

Буразналар толым-толым,
Кырларда җилләр исә.
Кара-зәңгәр туфрагында
Карашыңнан гөл үсә.

Ә таулары ап-ак яллы
Болытларны тышаулый.
Абагалар чәчәк ата,
Кара урманнар шаулый.

Күкеләр дә башка монда,
Еллар санын сорарга.
Уйласаң син, түземле бул
Меңгә кадәр санарга.

Суларында кояш йөзә,
Толымнарын таратып.
Үзәннәрдә җилеп очкан
Атлары да канатлы.

Урманында чишмәләре
Телләреңне чишәрлек.
Көлмәс булсаң, көлдерергә
Шүрәлеләр җитәрлек.

Кармак сала малайлары
Төннәрен менеп Айга,
Ышанмыйча сез сорарсыз:
– Чынлап, андый җир кайда?
Сер итеп әйтәм алайса:
– Аз-на-кай-да!..

Рәссам Иван ВОРОБЬЕВ





Тәгәри китте йомгагым...

Мин әле нишләп соң утырам,
Кулыма тальян-гармун тотып.
Әнинең:
– Онытма, су апкайт! –
Дигәнен бөтенләй онытып...

Шагыйрь Абый сөйли:

– Мин өстәл янында рәсем ясап утырам. Тышта буран кайный, вакыт-вакыт карлы итәге белән тәрәзәгә килеп сарыла. Мич артында тыйнак кына чикерткә сайрый. Стенада күкеле сәгать келт-келт вакыт саный. Әни ястыкка аркасын терәп утырган да оек бәйли. Песи анының йомгагын караваттан тартып төшергән, тәгәрәтеп, кинәнә-кинәнә уйный. Бераздан әни ястыкка кырынаеп, калгып китә, кулындагы энә-җебе алъяпкычына төшә, шулчак иркенлек сизгән песи, әрле-бирле тәгәрәтеп, йомгакның җебен сүтә бара, сүтә бара... Гомер дә шулай, язмышың сүтеп барган йомгак артыннан әкияттәгечә: «Тәгәри китте йомгагым, күрмәдеңме, әбекәй?» дигән шикелле, һаман саен киләчәгеңә ашкынып, елларны ерып барасың да барасың...

Мәче нигә мыеклы?

– Әни, әни, әйт әле,
Мәче нигә мыеклы?

– Тычканнарны бик ерактан
Сизеп алсын өченгә.


Мыек түгел, антенна ул
Безнең елгыр мәчегә.

– Әни, әни, алай булгач,
Мәче телевизормы?



Марсель Галиев – башкалардан бик нык аерылып торган язучы. Ул бөтен яктан аерылып тора: теле белән дә, стиле белән дә. Бик талантлы язучы. Барысыннан да әһәмиятлерәге, миндә кызыксындыру тудырган сыйфаты шул: ул берәүне дә кабатламый, берәүгә дә иярми. Аның һәр нәрсәгә үз карашы, үз мөнәсәбәте. Бу дөньяның, тормышның яңа якларын ача белүе һәм шул күргәненә карата үзенең мөнәсәбәте, саф фикере булуы белән ул башкалардан нык аерыла һәм шуңа күрә ул кызыксыну уята. Кызыксыну уяту – бу бик мөһим мәсьәлә... Безнең әдәбиятта гомер буе бик күп язып та кызыксыну уята алмаган әдипләр дә бар...

Әмирхан ЕНИКИ.



Көзге каршында

Үзен күргәч тә көзгедә
Песи аптырап калды.
Борынга борын тидереп,
Иснәшеп тә карады.
Әмма таныш түгел песи
Горур иде, шук иде,
Көзгедән килеп чыгарга
Исәбе дә юк иде.
Шуннан песи аны эзләп,
Көзге артына чыкты,
Аннан да таба алмагач,
Мыеклы йөзен чытты.
Көзгедәге песине ул
Бик ошатты – аңладым.
Песи телен белмәгәч, мин:
«Көзгедә дә син үзең бит», –
Дип аңлата алмадым.

Шагыйрь Абый мәче халкын бик ярата икән, әйемегез?! Белеп-сизеп торабыз, аларны сез дә яратасыз, әлбәттә. Сөекле дусларыгыз белән бергә төшкән кызыклы фотосурәтләрегез дә бардыр әле?! Журналыбызның «Мин бит бу!» сәхифәсе сездән аларны көтеп кала.



«Сәхнә»без түренә эленгән ак экранда Шагыйрь Абыйның гаиләсе белән бергә төшкән фотосурәте пәйда булды.



Шагыйрь Абый хатыны Динә ханым белән кызы Зөлфия янәшәсендә.

Балачак сурәтләре

Балачакның кадерле, самими сурәтләрен санап бетерерлекмени!

Мунча кергәндә ләүкә астында чуар түшен мимылдатып утырган бакадан курка идем. Ә ул – сәйлән күзле Мунча Иясе булган икән лә... Абзар Иясенең төн чыгуга ат ялын унике толымга үреп куюы... Җилле көндә морҗаның улавын җенгә сылтап юрган астына керүләр... Әрекмән яфрагына җыелган чык суына «баткан» кырмысканы коткару... Чәчәк таҗына кунган бал кортының аякларын ышкый-ышкый сутлы серкә җыюы дисеңме...

...Бары да хәтердә: капка шыгырдавы, әти-әнинең тавышы, күз карашы, күрше-күләннәрнең йөз рәвеше, авылның ярлы-ягымлы манзарасы – болар минем күңелне юатып, илһамга баетып торучы истәлекләр.

«Экран»да фоторәсемнәр янә бер-бер артлы пәйда була тора. Ул сүрәтләрдән сезгә таныш йөзләр карый...









Кадерле дуслар!

Әлеге фотосурәтләрдәге шәхесләр хакында сез ниләр беләсез? Аеруча кызыклы язмалар юллаучыларны күңелле сюрпризлар көтә!

Адресларыгызны, исем-фамилияләрегезне тулы һәм дөрес итеп язарга онытмагыз.



Атилла оныгы!

Япан дала.

Рухы – бөркет. Моңы – җил. Маягы – балбал.

Җәяүле диңгез син, олуг дала!

Әнә ул – еракта, бик еракта ак җилкән тибрәнә. Якынайган саен ерагая, ерагайган саен якыная бара. Менә ул янәшәдә генә... Киез түбәтәйле, биленә кушак буган ак күлмәкле Ак бабай балбал күләгәсендә утырган малай белән дала телендә исәнләшә. Кулында бик иске йөгән: каешлары яргаланган, бизәкле көмеш тамгалары куныкланган, алтын авызлык тимерләре генә дәртле зеңгелдәшә.

– Кая болай юл тотасың, Ак бабай? – ди балбаллы малай.

– Юлым туры, улым, Кояш чыгышыннан – Кара якка. Кояш баешыннан – Ак якка. Йөгәнемне тапшырырдай малай эзләп барышым...

– Кемгә кирәк ул, бабакай! – дия-дия малай көлә.

– Ат тояклары кытыклап тормаса, дала йөрәге тибүдән туктар, улым.

Малай мут елмаеп торган картка мәзәксенеп текәлде. Кинәт Ак бабайның күзләрендә бөркет карашы яшьнәп китте, тавышы да корыч чыңына әверелде. Малай, эсселе-суыклы булып, балбалның җылы ташына сыенды.

– И-и-и, улым, улым... Дөнья куласа... Күчәре урыныннан күчәр дә... Вакыт күчәреннән төшәр дә... ас дигән өс булыр, өс дигән ас булыр; уң дигән сул булыр, сул дигән уң булыр; тыш дигән эч булыр, эч дигән тыш булыр.

Аннарымы... Аннары... ут өстергән утны тыеп, йоталса күңеленә, сабырлык иңәр Җир йөзенә. Төн киселеп көн туар. Кояш җиле җим булып, җирдән шытар им булып. Ком китәр дә су калыр, су китәр дә ком калыр.

Аннарымы... Аннары... яшәү дигән газаплы да, саваплы да бу уен яңабаштан башланыр. Малайлар хыялы – ат булыр. Садакларга ук тулыр. Җәя кереше тартылыр. Тезген тоткан иярле ир ил тәхетенә утырыр.

Ак бабай шулай диде дә тынып калды. Малай тәненең җылына баруын тойды. Аңа рәхәт булып китте. Ак бабай аңа хәйләкәр көлемсерәп карады да:

– Сүземне кайсы кыйтгадан башлаган идем әле? – диде.

– Йөгәнне бирердәй малай...

– Әйе шул, әйе... Иртәрәк әлегә, иртәрәк... Йолдызлар тулып пешмәгән, төшәсе җиргә төшмәгән...

Бераздан Ак бабайның талгын җилгә кушылып моңлануына малай изрәп калгып китте. Күпме вакыт шулай узгандыр: айлармы, еллармы, әллә мизгел генәме?..

– Мин сине таныдым, бабай. Мин сине таныды-ы-ым!

Кинәт Ак бабай, иелеп, аның башыннан сыйпады да мәһабәт тау булып аягүрә басты. Тавышы хәтәр күкрәү булып яңгырый башлады:

– Син – Атилла оныгы! Беркайчан да хәтереңнән җуйма! Син – Атилла оныгы! Күпме Хода бәндәләре, үзенең Атилла оныгы икәнен онытып, чит түтәлләрне сугара, мескен кавемнәргә баш ора. Син үзеңнең Атилла оныгы икәнеңне белеп үссәң, буең да, уең да бер карышка биегрәк булыр. Онытма: син – Атилла оныгы!

Малай бу гасабилы тавыштан сискәнеп уянды. Тирә-юньдә һичкем юк, тып-тын. Малайның йөрәге дөп-дөп тибә башлады. Күкрәгендә гүя канатларын киергән бөркет очарга талпына, киңлек даулый иде.

«Мин – Атилла оныгы!»

Малай, үзалдына горур пышылдап, торып басты да, шаккатып, балбалга карады. Иртән генә бу таш һәйкәл белән үлчәнгән иде, нәкъ бер буйда иде бит ул... Хәзер әнә балбал бер башка тәбәнәгәеп калган.

Үсмер егет, уң кулын йодрыклап чөйде дә:

– Мин – Атилла оныгы! – дип, далага кычкырды.

Җәяүле диңгез өстеннән җил йомгагы булып кылганнар йөгерә – дала дулкыннары. Шул дулкыннар арасында, ерагайган саен якынаеп, якынайган саен ерагаеп, ак җилкән тибрәнә.

Бөек дала хәтере...



Сез борынгы бабаларыбыз турында, шулай ук, нәсел-нәсәбегез, шәҗәрәгез хакында ниләр беләсез? Бу хакта сезгә өлкәннәр белгәннәрен мавыктыргыч итеп сөйләрләр дип ышанып калабыз.



Шагыйрь Абыйның тамаша ахырында әйткәннәре:

– Син, яланаяклы бала! Олыларча, кулларыңны артка куеп тузанлы юлга баскансың да, пирамида булып күтәрелгән тауга карап торасың. Зәңгәр тау – ераклыгы белән серле, серлелеге белән ерак, ә ераклык үзенә тарта, ашкындыра, каядыр әйди.

Синең өчен зур шәһәрләр, илләр бары тик шул тау артында гына. Зәңгәр күк гөмбәзе астында, офык белән чикләнгән түгәрәкнең нәкъ уртасында торасың, имеш. Синең шул офык пәрдәсен күтәрәсең, чит дөньяларга күз саласың килә. Җир белән күк кушылган урынга кулыңны сузып йөгерәсең, йөгерәсең, ниһаять, тауга менеп җитәрсең, ә офык һаман шул ераклыкта калыр. Син һаман шул зәңгәр түбә белән ябылган күк астындагы түгәрәк мәйдан уртасында...

Беркөнне зәңгәр экранда син Җир шарын якыннан күрерсең. Баксаң, шулкадәр кечкенә икән бит ул, һәм никадәр зур да...

Син, гаҗизләнеп, олыларга мөрәҗәгать итәрсең.

– Чиксезлек нәрсә ул?

– Галәм.

– Ә галәм нәрсә?

– Бихисап йолдызлар, планеталар, кояшлар.

– Кояш бер генә булмыймыни?

– Кояшлар күп, балам.

– Ә мин ничәү?

– Бер генә. Әтиең дә, әниең дә бер генә. Туган илең дә...

Син әле күп сорауларга өлкәннәрнең дә җавап таба алмавын белмисең. Синең өчен әле өлкән кеше уйларга, эшләргә, калкан булып сине сакларга тиеш дип уйлыйсың. Һәм беркөнне... син өлкән кешенең урынын алачаксың.

Җиргә ташчылар җитми. Шагыйрьләр, игенчеләр, тукучылар, рәссамнар җитми. Шуларның берсе – син булырсың. Максатыңа ирешү – сәләтеңә, белемеңә, тырышлыгыңа бәйләнгән.

– Читтән караганда Җир шары нигә балкып күренә?

Син аңа үзеңчә җавап табарсың. Миллионлаган кешеләр күзендә чагылган кояш нурларының балкышыннан ул, диярсең син.

Туган тел

Бөек тә син, боек та син,
И туган тел, туган тел,
Күп гамәлләр кылган тел!
Аргамаклар җилеп чапкан,
Былбыл сайрап кунган тел.

Елатасың, юатасың,
И туган тел, туган тел,
Кәүсәр сулар юган тел!
Әткәм нигез ташы куйган,
Әнкәм бишек корган тел.

Уйлатасың, уятасың,
И туган тел, туган тел,
Дәрья булып тулган тел!
Шанлы, данлы дәверләрнең
Хөкемдары булган тел.

Талымлы син, ягымлы син,
И туган тел, туган тел,
Халкым кебек уңган тел!
Күктән иңгән иман нурын
Мәңге саклый торган тел!



Күңелле тамаша тәмам. Шагыйрь Абыйга бездән – алкышлар, чәчәк бәйләмнәре!..

Сәләват күпере

4(205) — 2007

ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ТАТМЕДИА» МАССАКҮЛӘМ КОММУНИКАЦИЯЛӘР АГЕНТЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ һӘМ РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ.
1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛИ: АГЕНТСТВО РТ ПО МАССОВОЙ КОММУНИКАЦИИ «ТАТМЕДИА», ПРАВЛЕНИЕ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ РТ И КОЛЛЕКТИВ РЕДАКЦИИ.
Основан в 1990 году.
На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Диләрә НӘҮРҮЗОВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта Алла АЙСИНА рәсеме

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кечә яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.
E-mail: salavatkupere@mail.ru

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе.

Казан, Декабристлар урамы,2 нче йорт.

Производствога бирелде 11.04.2007 ел.
Басарга кул куелды 11.04.2007 ел.
Кәгазь форматы 84x108 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басылды.
Тираж 12307 данә. Заказ С-440.

Санны әзерләүчеләр:
З.Хөснияр, В.Нуриев, Л.Лерон, Ф.Муллахмәт, М.Галиев, Н.Шаһиев, Н.Акмал, З.Вакказова, Г.Сабирова, А. Вакказов.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953



Марсель ГАЛИЕВ

Апрель

Апрель кары челтәрләнгән.
Кояш күзне чагып ала.
Кошлар оча әйлән-бәйлән.

Чана юлы өзек-өзек.
Тиздән кайта сыерчык, дип
Чыпчык сайрый өзеп-өзеп.

Йомшак исә таң җилләре.
Биләүдәге бөреләрдә –
Яшел яфрак өлгеләре.

Тиште бозны кояш нуры,
Купты җирдә гөрләвекләр,
Һәм башланды кошлар хоры.

Минем җылы куян бүрек:
– Кышка кадәр сау бул! – диеп,
Кунаклады чөйгә менеп.